ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ______________ с. Верхний Услон ______________ КАРАР

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесенең
2016 елның 01 апрелендәге 355 номерлы
«2016-2018 елларга Татарстан
Республикасы Югары Ослан муниципаль
районында кече һәм урта эшкуарлыкны
үстерү» программасын раслау турында»
карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 04 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «2016-2018 елларга Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең 01.04.2016 елдагы 355 номерлы карарының 2016-2018 елларга Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү программасына 1 нче кушымта өлешендә үзгәрешләр кертергә.
2. 2016-2018 елларда Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү программасына 1 нче кушымта текстын әлеге Карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль-икътисадый үсеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Л.С. Хәкимҗанов

Әзерләде һәм бастырды
О.А.Сельская